**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 май № 306

г. Казань

«Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы ведомствоара комиссиясен төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Заманча шәһәр мохите формалаштыру буенча Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм муниципаль программаларга ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 10 февраль, 169 нчы карары нигезендә «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасында проектны гамәлгә ашыру үтәлеше барышын тикшерүдә тоту һәм яраштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы ведомствоара комиссиясен төзергә.

2. «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәлә) расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\306.doc